Шимбә
20
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 42 (6764)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һәм КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һәм ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

1942 нче авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенең бурычлары турында

ВКП (б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карары

13 — 16 февраль, 1943 ел

«1942 нче авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенең бурычлары турында» ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш А. Г. Колыбановның докладын тыңлап тикшергәннән соң, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX пленумы түбәндәгеләрне әйтеп үтә:

Немец-фашист басып алучыларга каршы сугыш нәтиҗәсендә килеп чыккан кыенлыкларга (авыл хуҗалыгында эш кулларының, җигүле тарту көченең, тракторларның һәм автомашиналарның саны кимүгә) карамастан, Татарстан АССР колхозларының һәм совхозларының шактый өлеше үткән елгы төп авыл хуҗалыгы эшләрен 1941 нче елга караганда оешканрак төстә үткәрде. Көзге чәчү буенча дәүләт планы 109,9 процент итеп үтәлде, терлек азыклары силослау планы арттырып үтәлде, тунга сөрү 1941 нче елга чагыштырганда 273.000 гектарга артыграк үткәрелде.

Ләкин гомумән республикада иң әһәмиятле авыл хуҗалыгы эшләрен үткәргән чакта бик зур кимчелекләргә юл куелды. Бу кимчелекләр күп кенә план заданиеләрен үтәмәүдән, язгы чәчүдә, утауда, пар җирләрен сөрүдә һәм эшкәртүдә, ашлык сугуда, тунга сөрүдә билгеләнгән срокларны өзүдән гыйбарәт булды.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы ашлык һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү эшендә күп кенә партия, совет, җир һәм әзерләү органнарының гадәттән тыш начар эшләгәнлекләрен, шуның нәтиҗәсендә бер генә районның да дәүләткә ашлык тапшыру планын үтәмәгәнлекләрен күрсәтеп үтә.

Ашлык әзерләү эшендә барыннан да бигрәк Кызыл Армия, Биләр, Баулы, Ворошилов, Яна Чишмә, Кузнечиха, Куйбышев, Лаеш, Бәгелмә, Әлки, Чистай һәм Тәмте районнары артта калалар.

Ашлык әзерләү ягыннан хәлнең мондый гафу ителмәслек төстә булуы бу районнардагы һәм күп кенә башка районнардагы җитәкчеләрнең саботажникларга каршы большевистик көрәш алып бармауларыннан, дәүләткә каршы булган тенденцияләр белән килешүләреннән, ә кайбер районнарда җитәкчеләрнең үзләренең дә артталык настроениеләренә бирелгән булуларыннан һәм ачыктан-ачык саботаж юлына басканлыкларыннан килеп чыккан (Биләр районында Демидов һәм Скотников, Буденныйда Әхмәтов һәм Баскаков, Баулыда Ананьев, Беренче Майда Юсупов, Кызыл Армия районында Закиров һәм Макаров, Вахитов исемендәге совхозда Зәйнуллин һәм Юсупов, Тат. Ялтан МТС ында Газизов һәм башкалар).

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, прокуратура һәм суд органнарының үзләренең эшләрен СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1942 нче ел 23 нче ноябрь таләпләренә туры китереп үзгәртеп кормаганлыкларын, ашлык әзерләү эшенә саботаж ясаучыларга, ашлыкны әрәм-шәрәм итүгә һәм урлауга каршы соңгы вакытларга кадәр бөтенләй җитәрлек көрәш алып бармаганлыкларын, еш кына мондый эшләргә бюрократларча формаль караганлыкларын, ул эшләрне карауда волокита тудырганлыкларын әйтеп үтә.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, районнардагы партия һәм совет оешмаларының, МТС ларның, район җир бүлекләренең, Татарстан АССР Наркомземының һәм совхозлар трестларының авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүләрендә җитди кимчелекләр булганлыктан районнарның берсе дә иген уңышы буенча дәүләт планын үтәмәгәннәр, дип саный. Колхозларның һәм совхозларның бер өлеше күп кенә еллар буена рәттән гадәттән тыш түбән уңыш алып килә, бик күп югалтуларга юл куя һәм авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыру буенча дәүләт каршында бурычлы булып килә.

Ворошилов, Әлки, Кузнечиха, Лаеш, Куйбышев, Биләр, Алабуга, Чепья, Тәмте, Алексеевский, Кама тамагы районнарында, Татмолсемтрестның «Комсомолец» һәм Алабуга совхозларында, Свиноводтрестның «Большевик» совхозында иген уңышы ягыннан эш ачыктан-ачык начар тора.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы иген уңышы түбән булуның төп сәбәпләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт дип саный: республика колхозлары һәм совхозлары агротехника чаралары планнарын ел саен үтәми киләләр, төп авыл хуҗалыгы эшләренең срокларын озакка сузалар, тунга сөрү планнарын үтәмиләр, пар җирләрен һәм чәчүлекләрне начар тәрбиялиләр, шулай ук тракторлар паркының эшләве һич тә канәгатьләнерлек түгел.

1942 нче елны сабан басуының 88 проценты җирне яз көне сөреп кенә чәчелгән, чиста пар җирләре сөрүнең бары тик 12 проценты гына билгеләнгән агротехника срокларында үткәрелгән, шуның белән бергә, пар җирләрен соңыннан тәрбияләп тору булмаган (пар җирләрен беренче тапкыр культивацияләү 56.000 гектар җирдә, яки 7,8 процентка, икенче тапкыр культивацияләү 1.800 гектар җирдә, яки 0,2 процентка гына үткәрелгән). Бөртекле культуралар чәчелгән 700.000 гектардан артык җир бөтенләй уталмый калган. Техник, майлы культуралар һәм бигрәк тә тары чүбен утау гадәттән тыш начар оештырылган. Туфракның эшкәртелүе түбән сыйфатлы (сай сөрү, чи калдыру), чүпле участокларга чәчү, чәчүлекләрне тиешенчә тәрбияләмәү, чисталыгы ягыннан кондициясез орлык чәчү колхоз һәм совхоз кырларының бик нык чүпләнүенә сәбәп булган.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы түбәндәгеләрне күрсәтә: СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1942 нче ел 11 нче июль карары һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм ТАССР Совнаркомының махсус кисәтүе булуга да карамастан, күп кенә колхоз, совхоз һәм район оешмалары җитәкчеләренең орлыклык участоклар билгеләүгә һәм аларны тәрбияләп торуга җинаять төсендә караганнар, орлыклык участокларда барлык агротехника чараларын тулысынча үткәрүне тәэмин итмәгәннәр, алардагы игеннәрне соңга калып җыеп алганнар һәм соңга калып сукканнар, нәтиҗәдә орлыклык участокларның иген уңышы кимегән һәм чәчүлек материалның сыйфаты начарланган. Соңгы елларда колхоз һәм совхозларның шактый җирләренә кондициясез орлыклар чәчү бары тик орлыкчылык эшенә бәя биреп җиткермәү нәтиҗәсендә генә килеп чыккан.

Гомумән республикада көзге чәчү планы арттырып үтәлгән булуга да карамастан, планга карата бары 50 проценты гына агротехника буенча яхшы срокларда үткәрелгән, ә Лаеш, Алексеевский, Баулы, Кызыл Йолдыз, Столбище һәм Тәкәнеш районнарында 25 проценттан 37 процентка кадәр генә яхшы срокларда үткәрелгән. Үткән елны республикада тунга сөрү планы 57,3 процентка гына үтәлгән, камыл лущить итү бөтенләй үткәрелмәгән.

Авыл хуҗалыгы эшләрен үткәрү срокларының озакка сузылуына МТС ларның һәм колхозларның зур күпчелегендә тракторлардан һәм комбайннардан файдалануның начар булуы сәбәп булган. Татарстан АССР да трактор эшләре буенча еллык план 59,1 процентка, комбайннар белән урып-җыю планы 44,4 процентка һәм бөртекле ашлыкларны сугу планы 48,5 процентка гына үтәлгән. Газогенераторлы тракторлардан файдалану чиктән тыш начар оештырылган (план 32 процентка гына үтәлгән).

МТС лар эшенең мондый йомгаклары ТАССР Наркомземының, политсекторның, МТС политбүлекләренең, ВКП(б) райкомнарының һәм район советлары башкарма комитетларының машина-трактор станцияләренең эшләренә һәм бигрәк тә механизатор кадрлар әзерләүгә көндәлек оператив җитәкчелек итмәүләре нәтиҗәсендә, тракторлар паркының кыр эшләренә канәгатьләнерлек әзерләнмәве нәтиҗәсендә, тиешле техник уходның булмавы нәтиҗәсендә, хезмәтнең начар оештырылуы нәтиҗәсендә килеп чыккан һәм бу хәл тракторларның массовый төстә эшсез торуларына һәм ягулыкны гаять күп тотуга китергән.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, МТС ларның һәм совхозларның политбүлекләре тарафыннан үткәрелгән яхшы эшләр булу белән бергә әле һаман да кайбер политбүлекләрнең ВКП(б) Үзәк Комитетының 1941 нче ел 17 нче ноябрь карары белән үз алларына куелган бурычларны начар үтәүләрен, МТС ларда, совхозларда һәм колхозларда тәртип урнаштырмаганлыкларын, колхозларның һәм совхозларның дәүләт каршындагы йөкләмәләрен вакытында үтәүне тәэмин итмәгәнлекләрен һәм кадрларның, колхозчыларның, МТС һәм совхоз эшчеләренең киң массасын тәрбияләү буенча һич тә җитәрлек эш алып бармаганлыкларын күрсәтеп үтә.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, күп кенә районнарда колхозларның җитәкче кадрларын (колхоз правлениеләре председательләрен, хисапчыларны, бригадирларны, звено җитәкчеләрен) җитди төстә сайлап алу юклыкны, ВКП(б) райкомнарының, район башкарма комитетларының һәм МТС политбүлекләренең алар белән көндәлек эш алып бармауларын күрсәтеп үтә.

ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы, ВКП(б) Өлкә Комитетының кадрлар бүлеге, ТАССР Наркомземы (наркомның кадрлар буенча урынбасары иптәш Үзбеков), совхозлар трестлары директорлары һәм политсекторлар җитәкче авыл хуҗалыгы кадрларын сайлап алу, өйрәнү һәм урнаштыру белән һич тә җитәрлек шөгыльләнмиләр, аларга эштә булышлык итүләре начар дип саный.

Партия, совет, җир органнарының һәм колхозларның күп җитәкчеләре 1942 нче елны канәгатьләнерлек эшләмәүдән үзләре өчен кирәкле нәтиҗәләрне ясамаганнар һәм 1943 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләрен, аерым алганда язгы чәчүне үткәрүгә әзерлекне чын-чынлап оештырмаганнар.

Шушы елның 10 нчы февраленә МТС лардагы тракторларның 58,7 процентына гына, тракторга тагыла торган сабаннарның 35,7 процентына гына, чәчү машиналарының 46,8 процентына һәм культиваторларның 47,3 процентына гына ремонт ясалган. Чәчүлек орлык туплау начар бара, орлыкларның 41 проценты гына триер аркылы чистартылган, әзерләнгән орлыкның 38,3 проценты гына орлык-контроль лабораторияләрендә тикшерелгән. Орлыклык бәрәңге планга карата 43 процент кына тупланган. Чәчү өчен азык бәрәңгесенең кисентеләрен әзерләү эшенә республикада асылда керешелмәгән.

Колхозларда авыл хуҗалыгы инвентарена ремонт ясау эше тагын да начаррак тора: 1 нче февральгә сабаннарның 27,6 процентына, тырмаларның 40 процентына, чәчү ма-

(Дәвамы 2 нче биттә).

1942 нче авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенең бурычлары турында

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карары

(Дәвамы. Башы 1 нче биттә).

шиналарының 26,7 процентына һәм культиваторларның 33,4 процентына гына ремонт ясалган.

Барлык системалардагы совхозларда тракторларга, тагылма инвентарьга ремонт ясау һәм чәчүлек орлык туплау эше шундый ук хәлдә тора. 1 нче февральгә Свинсводтрест совхозларында тракторларның 45,9 процентына, Татмолсемтрест совхозларында 48,5 процентына һәм Спирттрест совхозларында 60,2 процентына гына ремонт ясалган.

Күп кенә МТС ларның һәм совхозларның директорлары һәм политбүлек начальниклары механизатор кадрлар әзерләүгә бәя биреп җиткермәүләрен дәвам иттерәләр. Механизация мәктәпләренә әле хәзергә кадәр курсантлар тулысынча тупланмаган. Укытуның сыйфаты түбән. Күп кенә хәлләрдә ВКП(б) райкомнары секретарьлары кадрлар әзерләү эшеннән читтә торалар, булган кимчелекләрне бетерү өчен кискен чаралар күрмиләр.

Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында шулай ук кышкы агротехника чаралары планын үтәү ачыктан-ачык өзелү куркынычы астында тора: тиреснең бары 15,9 проценты гына чыгарылган, көл 6,5 процентка гына, кош тизәге 6,2 процентка гына җыелган, ашлама өчен торф 0,1 процент кына әзерләнгән, кар тоту планы 19,5 процентка гына үтәлгән.

Атларны тәрбияләү һәм алардан файдалану турында ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Татарстан АССР Совнаркомының карары булуга да карамастан, районнарның зур күпчелегендә язгы чәчүгә атларны әзерләү белән чиктән тыш начар шөгыльләнәләр. Күп кенә колхозларда атлардан ерткыч төстә файдалану аркасында алар ябыклануга кадәр китереп җиткерелгәннәр, атларның бер өлеше бөтенләй сафтан чыккан. Мөгезле эре терлекләрне авыл хуҗалыгы эшләренә билгеләп кую һәм өйрәтү асылда башланмаган.

1943 нче елгы язгы чәчүгә уңышлы әзерләнүне һәм аны иң кыска срокларда, агротехника ягыннан югары дәрәҗәдә үткәрүне тәэмин итү теләге белән, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты пленумы карар бирә:

1. Татарстан АССР Наркомземын (иптәш Хөсәеновны) һәм совхозлар трестлары директорларын (Дубей, Урманов һәм Щербаков иптәшләрне),—ун көн срок эчендә 1943 нче елга авыл хуҗалыгы эшләре планын төзергә мәҗбүр итәргә һәм соңыннан бу планны ТАССР Совнаркомында һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросында раслурга.

2. ВКП(б) райкомнарын, район советлары башкарма комитетларын, җир органнарын,—кичекмәстән 1943 нче елга авыл хуҗалыгы эшләре планнары төзүдә әзерлек эшенә керешергә һәм контроль заданиеләр алганнан соң 5 көн срок эчендә планнарны һәрбер колхозга җиткереп, аларны актив белән, шулай ук колхозчылар җыелышында киң күләмдә тикшерүне оештырырга мәҗбүр итәргә.

3. Республика колхозларында һәм совхозларында ашлык тапшыру темпларының гафу ителмәслек дәрәҗәдә түбән булып калуда дәвам итүен, ә күп районнарда ашлык тапшыруның асылда тукталганлыгын күрсәтеп, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы барлык райкомнарның секретарьларыннан, башкарма комитетларның председательләреннән, район уполнаркомзагларыннан, МТС һәм совхоз директорларыннан һәм аларның политбүлекләре начальникларыннан билгеләнгән заданиеләрнең 10 нчы марттан соңга калмыйча үтәлүен тәэмин итәрлек ашыгыч чаралар күрүне кискен төстә таләп итә.

4. ВКП(б) райкомнарын, район советлары башкарма комитетларын, МТС һәм совхоз директорларын һәм политбүлек начальникларын, ТАССР Наркомземын һәм совхоз трестларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) шушы елның 20 нче февраленнән соңга калмыйча, бөтен ашлыкны сугып бетерергә, кирәк булган урыннарда сугу агрегатларын бер хуҗалыктан икенче хуҗалыкка күчереп торырга;

б) барлык колхозларда һәм совхозларда, СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1942 нче ел 11 нче июль карарына тулысынча туры китереп, бөртекле ашлык, кузаклы һәм техник культуралар һәм үлән орлыклары туплауны, аларны чистартуны һәм сортлауны шушы елның 15 нче мартына тәмам итәргә, бу эшләр өчен колхозларда, МТС ларда, совхозларда һәм әзерләү оешмаларында булган барлык орлык чистарту машиналарыннан файдаланырга, иң гади чистарту әйберләрен (кружалы, иләк, горка) киң күләмдә кулланырга, аларның орлык чистартуда тәүлегенә кимендә 16 сәгать эшләүләрен тәэмин итәргә;

в) чәчүлек орлыклар туплау планын шушы срокка үтәү максаты белән: начар сугу аркасында күп орлык югалган колхозларда кабат сугу үткәрергә, үзләренең каралты тирәсе участокларында чәчүлекләре булган, яки колхозда эшләгән өчен җитәрлек кадәр ашлык һәм бәрәңге алган колхозчылардан, тракторчылардан, комбайнчылардан һәм башка работниклардан бөртекле, яшелчә культуралары орлыкларын һәм орлыклык бәрәңге җыюны һәм бурычка алып торуны, шулай ук ашлык тапшыру буенча үзләренең дәүләт каршындагы йөкләмәләрен үтәгән колхозлардан бурычка орлык алып торуны оештырырга;

г) ашлык тапшыру планын үтәгән колхозларда сабан культуралары орлыкларының җитмәгән өлешен азыкка тотылачак уҗым культураларына колхозлар арасында алмашуны һәм чыгышы түбән булган орлыкларны чыгышы яхшы булган, ләкин фуражга һәм азыкка дип әзерләнгән орлыкка алмаштыруны кичекмәстән башларга;

д) тупланган чәчүлек орлыкларны контроль-орлык лабораторияләрендә тоташтан тикшереп чыгарга, беренче тапкыр тикшерү 25 нче февральдән соңга калмыйча, ә икенче кат тикшерү язгы чәчү башлануга 15 көн калуга үткәрелергә тиеш;

е) һәрбер колхозда һәм совхозда орлыкларны агулау өчен кирәк булган машиналарны һәм инвентарьны исәпкә алырга һәм аларга ремонт ясауны һәм эшкә әзерләүне тәэмин итәргә; орлыкларны агулау өчен күпме һәм нинди агу-химикатлар кирәклекне белергә һәм чәчү башлануга 20 көн калганда аларны хуҗалыкларга ташып куярга;

ж) орлыклык материалны төгәл учетка алуны һәм саклауны тәэмин итәргә, орлыкларны бозуда, урлауда һәм әрәм-шәрәм итүдә гаепләрне бик каты җавапка тартырга;

з) азык өчен калдырылган бәрәңгеләрдән чәчүлек кирәкләренә кисентеләр әзерләү буенча һәрбер район, совхоз һәм колхоз өчен билгеләнгән планның һичбер сүзсез үтәлүен тәэмин итәргә.

5. МТС һәм совхоз директорларын һәм политбүлек начальникларын, ВКП(б) райкомнары секретарьларын, район советлары башкарма комитетлары председательләрен, ТАССР Наркомземын, трестларның директорларын һәм политсектор начальникларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) тракторларга, авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьга ремонтны шушы елның 15 нче мартыннан соңга калмыйча югары сыйфатлы итеп тәмам итәргә, моның өчен аларга ремонт ясау эшенә җитәрлек кадәр санда тракторчыларны тартырга, эчке мөмкинлекләрдән иң күп күләмдә файдалануга, запас частьларны, металлны, инструментны саклык белән һәм экономия белән тотуга аеруча игътибар бирергә, барлык МТМ нарда, МТС ларда, совхозларда һәм колхозларда станок җиһазларының бөтен тәүлек буена эшләвен оештырырга;

б) язгы кыр эшләре башлануга иң күбе 15 көн калганда МТС ларның һәм совхозларның язгы чәчүне үткәрүгә әзерлекләрен, тракторчыларның әзерләнгәнлеген, кадрлар белән тәэмин ителгәнлекне, трактор бригадаларына участоклар беркетелгәнлекне, ягулык һәм май белән, заправка инвентаре, инструмент белән һәм культура-масса эше алып бару өчен кирәкле җиһазлары булган кыр вагоннары белән тәэмин ителгәнлекне тикшерергә;

в) колхозларда бар кадәр машиналарга, ат һәм кул инвентарена ремонт ясауны оештырырга, һәрбер колхозда тәҗрибәле колхозчылардан бик тизлек белән ремонт бригадалары төзергә. Тимерчеләрнең бик күп җитешмәвен искә алып, ремонт вакытына шәһәрләрдән һәм район үзәкләреннән колхозларга тимерчеләр җибәрергә, шулай ук яхшы җиһазландырылган алачыклары һәм квалификацияле тимерчеләре булган колхозларда күрше колхозларның инвентарена ремонт ясауны оештырырга;

г) 10 нчы марттан 25 енә кадәр булган вакыт эчендә колхозларның чәчүгә әзерлекләренә массовый смотр үткәрергә, тикшерү вакытында табылган кимчелекләрне тизрәк бетерү өчен кирәкле чараларны күрергә;

д) алдынгы агротехниканы үткәрү өчен, югары иген уңышы өчен көрәштә агрономнарның, тәҗрибә учреждениеләренең һәм авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү учреждениеләренең ролен һәм әһәмиятен күтәрергә; аларның колхозларга һәм совхозларга булышлыгын көчәйтергә; барлык колхозлар өчен агротехниклар әзерләргә.

6. ТАССР Наркомземын, совхозлар трестларын һәм Главнефтесбытның өлкә конторасын, — МТС ларга һәм совхозларга ягулыкны һәм майларны ай саен ташу һәм туплау буенча план төзергә, шуның белән бергә, ягулыкны еракта МТС ларга һәм совхозларга җибәрүгә, шулай ук газогенераторлы тракторлар өчен агач ягулык әзерләүгә аеруча игътибар бирергә мәҗбүр итәргә.

7. ВКП(б) ның Казан, Зеленодольск һәм Чистай шәһәр комитетларына һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының промышленность тармаклары буенча секретарьларына түбәндәге эшләрне тапшырырга:

а) бик тизлек белән, һәрбер бригадада 7—10 кеше исәбеннән, слесарьлардан, токарьлардан, тимерчеләрдән һәм электросварщиклардан 30—35 ремонт бригадасы төзергә һәм аларны, практик ярдәм күрсәтү өчен, ремонт ягыннан артта калучы МТС ларга һәм совхозларга бригадир (инженер яки техник) җитәкчелегендә җибәрергә;

б) 20 нче февральдән соңга калмыйча, заводларның, промышленность предприятиеләренең һәм промкооперациянең тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау өчен запас частьлар әзерләү һәм искеләрен яңарту буенча Татарстан АССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты билгеләгән планны үтәүләрен тикшерергә һәм планның тулысынча үтәлүе өчен барлык чараларны күрергә, ә Автотракторсбытка (иптәш Кәлимуллинга) — әзерләнгән запас частьларны предприятиеләрдән вакытында алуны һәм урыннарга җибәрүне тәэмин итәргә.

8. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы ВКП(б) ның күп кенә райкомнарының һәм район советлары башкарма комитетларының авыл хуҗалыгына җитәкчелек итүдәге яраксыз практикаларын, ягъни югары һәм ныклы иген уңышын яулап алу өчен тиешле чаралар күрмәүләрен, агротехника чараларын явыз ният белән бозучыларга либералларча карауларын гаепли һәм һәрбер колхоз һәм совхоз өчен билгеләнгән агротехника чаралары планын һичсүзсез үтәүне, авыл хуҗалыгы эшләренең срокларын бик нык саклауны, МТС ларның һәм совхозларның тракторлар паркыннан файдалануны кискен төстә яхшыртуны таләп итә.

9. Район җир бүлекләрен, колхоз правлениеләрен һәм совхоз директорларын мәҗбүр итәргә:

а) кыр эшләре башланганчыга кадәр барлык басуларны саламнан, көнбагыш сабакларыннан һәм чүп-үләннәреннән чистартырга, җирне башта чистартмыйча яз көне сөрүгә һичбер хәлдә дә юл куймаска;

б) язгы кыр эшләрен, бөтен җир өлгергәнне көтеп тормыйча, аерым участоклар өлгерә барган саен иртә срокларда сайлап алып үткәрә башлауны тәэмин итәргә, чәчү алдындагы эш белән чәчү вакытындагы эш арасында әзеклеккә юл куймаска;

в) туңга сөрелгән бөтен мәйданда һәм кара пар җирләрендә 2—3 көн эчендә яз көне әлбәттә иртә тырмалау үткәрергә; агротехника чаралары планын тулысынча үтәргә, язгы кыр эшләрен агротехника таләпләренә бик нык туры китереп үткәрүне оештырырга;

(Ахыры 3 нче биттә).

1942 нче авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенең бурычлары турында

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX нчы пленумы карары

(Ахыры. Башы 1—2 биттә).

г) бөртекле сабан культураларын кыска срокларда һәм югары сыйфатлы итеп, яровойлаштырылган орлыклар белән чәчәргә, бу эшкә тиешенчә әзерлек үткәрергә;

д) орлыклык участокларга иң яхшы җирләр билгеләүне тәэмин итәргә, аларны үрнәк булырлык итеп эшкәртергә һәм ашларга, аларда чәчүне бер—ике көн эчендә, иң яхшы вакытта үткәрергә. Орлыклык участокларны тәрбияләп торуны бригадалардагы махсус звеноларга тапшырырга.

10. 1943 нче елгы язгы чәчү нигездә җанлы тарту көчләренә шактый күп нагрузка биреп, яз көне сөрелгән җирдә үткәреләчәкне искә алып, ВКП(б) райкомнарын, район советлары башкарма комитетларын һәм колхозларның правлениеләрен,—кыр эшләренә тарту көчләрен әзерләү буенча барлык кирәкле чараларны күрергә, атларны һәм авыл хуҗалыгы инвентарен аерым колхозчыларга беркетергә мәҗбүр итәргә. 1 нче мартка кадәр барлык эш терлекләрен җентекләп карап чыгарга, аеруча көчсез атларны аерым группаларга куярга, аларны аерым тәрбияләүне һәм аерым ашатуны оештырырга. Чәчү эшләре башлануга 15 көн калганда барлык атларны ялга куярга. Язгы чәчү һәм пар җирләрен сөрү чорына кирәк кадәр фураж билгеләп куярга.

Колхозлардан, колхозчылардан һәм ялгыз хуҗалыкчылардан авыл хуҗалыгы эшләренә тартылачак мөгезле эре терлекләрне исәпкә алып, язгы чәчүдә барлык эш терлекләреннән файдалануны тәэмин итәрлек кадәр санда иске сбруйларга кышкы айлар эчендә ремонт ясарга һәм яңа сбруйлар әзерләргә.

11. Хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү һәм колхозларда хезмәт дисциплинасын ныгыту теләге белән ВКП(б) райкомнарын, район башкарма комитетларын һәм җир органнарын түбәндәге чараларны үткәрергә мәҗбүр итәргә:

а) бригадаларда һәм звеноларда хезмәтне оештыруның һәм учетка алуның нинди хәлдә икәнлеген, колхозчыларны бригадаларга һәм звеноларга бүлүнең дөреслеген, эш планнары төзелгәнлекне тикшерергә; звеноларны үзләренә беркетелгән участокларда эшләүләрен яңадан урнаштырырга һәм тәэмин итәргә;

б) кырчылыкта да, шулай ук терлекчелектә дә хәзерге эш нормаларын һәм хезмәт көннәре исәбе белән һәрбер эшкә куелган бәяне яңадан карап чыгарга, аларны намус белән үтәүче колхозчыларның эшләп чыгарулары дәрәҗәсенә кадәр күтәрергә;

в) эчке тәртип кагыйдәләре эшләргә һәм аларны колхозчыларның гомуми җыелышларында расларга, колхоз эшләрендә барлык колхозчыларның тулысынча катнашуына, шулай ук колхоз производствосының барлык тармакларында эш көнен тыгызлауга ирешергә.

12. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы ВКП(б) райкомнарының, район башкарма комитетларының, МТС һәм совхоз политбүлекләренең игътибарын җитәкче һәм массовый колхоз кадрлары әзерләүгә юнәлдерә. Моның өчен 1 нче апрельгә кадәр агротехника, хезмәтне оештыру һәм учетка алу мәсьәләләре буенча колхоз председательләренең, кырчылык һәм яшелчәчелек бригадалары бригадирларының, звено җитәкчеләренең, чәчүчеләрнең һәм сөрүчеләрнең курс-семинарларын үткәрергә.

Барлык урыннарда колхозчыларны һәм совхоз эшчеләрен стахановчылык мәктәпләрендә һәм агротехника түгәрәкләрендә массовый төстә өйрәтүне оештырырга, аларда укытучылар итеп агрономнардан, уку йортларының фәнни работникларыннан, иң яхшы колхоз председательләреннән, бригадирлардан, звено җитәкчеләреннән һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан файдаланырга.

13. Промышленность предприятиеләренең һәм оешмаларының күп кенә ярдәмче хуҗалыклары язгы чәчүне үткәрүдә бик начар әзерләнгәнлекне искә алып, пленум ВКП(б) ның шәһәр комитетын һәм шәһәр райкомнарын, предприятиеләрнең директорларын һәм оешмаларның җитәкчеләрен, партия оешмаларының секретарьларын, — бу эштәге кимчелекләрне бик тизлек белән бетерергә, язгы чәчүгә әзерлек һәм аны үткәрү эшенең барышына көндәлек контроль куярга һәм җитәкчелек итәргә, ТАССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Өлкә Комитетының 1942 нче ел 30 нчы декабрь карарын тулысынча үтәүне тәэмин итәргә мәҗбүр итә.

14. ТАССР Наркомземын һәм Наркомпросын, — вуз һәм техникум студентларын, шулай ук урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләрнең өлкән классларында укучыларны авыл хуҗалыгы эшләренә өйрәтү планын төзергә һәм аларны өйрәтү эшенә керешергә мәҗбүр итәргә.

15. Хатын-кызларны авыл хуҗалыгы эшләренә иң күп күләмдә тарту өчен һәрбер колхозда балалар бакчалары, ясләләр һәм плошадкалар оештырырга, аларга хезмәт күрсәтү өчен хезмәткә ярақлылыклары кимрәк булган колхозчы хатын-кызларны билгеләргә, бу эшкә укытучы хатын-кызларны тартырга.

16. Өлкә Комитеты пленумы ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросына, Ворошилов, Кызыл Армия, Куйбышев, Кузнечиха, Лаеш һәм Биләр районнарының артта калуларын бетерүгә аеруча игътибар бирергә, бу районнарны әзерлекле кадрлар белән ныгытырга, машина-трактор паркын аякка бастыру буенча һәрьяклап булышлык күрсәтергә тәкъдим итә. Бу районнарга, практик чаралар эшләү һәм аларның артта калуын бетерүдә булышлык итү өчен, ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм ТАССР Совнаркомының махсус бригадаларын җибәрергә.

17. ВКП(б) райкомнарын, МТС һәм совхоз политбүлекләрен,— колхозларда һәм совхозларда академик иптәш Т. Д. Лысенконың «Совет авыл хуҗалыгы фәненең якындагы бурычлары» дигән докладын өйрәнүне оештырырга, чәчүлек материалны яхшырту методларын, туфракны чәчү алдыннан эшкәртү юлларын, һәм академик иптәш Лысенко куйган башка положениеләрне тормышта киң күләмдә куллануны тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә.

18. ТАССР Наркомземын, Татгосиздатны, 1—2 ай эчендә, агротехника мәсьәләләре, терлекләрне тәрбияләү һәм ашату мәсьәләләре буенча брошюралар һәм листовкалар сериясе әзерләргә һәм басып чыгарырга мәҗбүр итәргә.

19. Күп кенә комсомол оешмаларының авыл хуҗалыгы эшләрен үткәрүдә катнашулары канәгатьләнерлек түгеллекне күрсәтеп, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы ВЛКСМ өлкә комитетын, район комитетларын һәм ВКП(б) райкомнарын,—комсомол оешмаларын активлаштыру өчен чаралар күрергә, аларның эшен 1943 нче елгы язгы чәчүгә һәм башка авыл хуҗалыгы эшләренә әзерлектә һәм аларны үткәрүдә актив катнашуга юнәлдерергә мәҗбүр итә.

20. ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы барлык партия, комсомол, совет һәм профсоюз оешмаларын,— масса арасында политик эшне, колхозларда, МТС ларда һәм совхозларда социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен киң җәелдерергә, партия-комсомол көчләрен хәлиткеч тармакларга урнаштырырга, язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп әзерләнүгә һәм аны үткәрүгә, югары һәм ныклы иген уңышы өчен көрәшкә, Кызыл Армиягә ярдәмне көчәйтүгә барлык колхозчыларны, колхозчы хатын-кызларны, МТС һәм совхоз эшчеләрен, авыл хуҗалыгы белгечләрен тупларга, немец-фашист басып алучыларны тизрәк һәм тәмам тар-мар итү өчен кирәк булган продукцияне фронтка тагын да күбрәк һәм күбрәк бирүне тәэмин итәргә мәҗбүр итә.

ПРОФСОЮЗ-КОМСОМОЛ ЧАҢГЫ КРОССЫ

Чепья чаңгычыларын каршылау

КЕНӘР, 19 февраль. (**Телефон буенча**). 18 нче февральдә, 16 сәгатьтә Чепья районыннан чаңгы эстафетасында катнашучылар каршы алынды. Иптәш Фәезев җитәкчелегендәге команда Кызыл юл район үзәгенә,—Кенәргә билгеләнгән вакыттан 2 сәгать элек килде. Эстафетада катнашучылар, һава шартларының начар булуына да карамастан, үзләрен яхшы хис итәләр.

Эстафетачыларны каршылау уңае белән митинг булды. Митингтан соң Яңа Кенәр мәктәбе укучыларының көче белән концерт куелды. Кызыл юл районыннан эстафетага Яңа Кенәр мәктәбенең укытучылары һәм укучылары катнашалар.

Кичә, 19 нчы февральдә, 8 сәгатьтә, Кызыл юл районы эстафетачыларына Әтнәгә китү өчен старт бирелде. Чаңгычыларга иптәш Фәйзуллин җитәкчелек итә.

А. САФИУЛЛИН.

БӘЙРӘМ АЛДЫННАН

Данлыклы бәйрәм — Кызыл Армиянең 25 еллыгы якынлаша. 3 нче номерлы фанера заводы коллективы үзенең бу бәйрәмгә карата алган йөкләмәләрен үтәүдә тырышлыгын тагы да арттыра төште. Һәркем бәйрәм көненә яхшырак бүләк әзерләү турында кайгырта.

Өч иптәш—Фәйзи Заһидуллин, Миңнул Гыйззәтуллин һәм Гариф Фәхретдиновлар элеккечә лущильщиклар арасында авангард булып саналалар һәм ярышта беренче урында баралар. Норманы 150-170 процентка үтәү—аларның көндәлек эш программасы. Чимал гаять кадерле хәзер, электр энергия һәм ягулык—тагын да кадерлерәк. Боларның барын да күз карасы шикелле саклап тотарга кирәк. Өч иптәш моны бик яхшы аңлыйлар һәм азрак энергия тотып, аз чималдан күп продукция бирү өчен көрәшәләр.

Кышкы шартлар белән бәйле булган кыенлыкларга карамастан, заводның күп кенә участоклары эш темпын байтак көчәйттеләр. Иптәш Бакиров участогы махсус фронт заказын вакытыннан элек үтәде. Икенче бер заказны үтәү буенча да зур җанлану сизелә. Чөнки, I нче квартал планын 15 нче мартка үтәргә кирәк!

Иптәш Морозов цехы яңа заданиe—ярты миллион данә шырпы пластинкалары эшләп чыгару заданиесен алды. Моның өчен хәзер махсус оборудование куела, һәм 23 нче февраль көненә беренче партия пластинкалар чыгарылачак.

Шул ук Морозов цехында эшләүче стахановчылар Сергеев, Сәйфетдинов, Иваницкий, Панина, Иватина иптәшләр бәйрәм хөрмәтенә алынган йөкләмәләрен арттырып үтәп киләләр. Алар һәркайсы да ярты айлык планны 150 дән алып 225 процентка кадәр үтәделәр.

Бу цехта фронт заказлары үтәлү белән бергә, киң куллану товарларын эшләп чыгаруда параллель рәвештә алып барыла. Соңгы айларда өстәлләр, табуреткалар, тумбочкалар эшләү яңадан башланды.

Производствода фронттагыча эшләү белән бергә, эшчеләр сугышчыларга бәйрәм бүләкләре алу өчен 45.000 сум акча җыйнадылар һәм танклар колоннасы төзү фондына һәрберсе айлык эш хакының 25 процентын бирделәр.

Бәйрәмгә әзерлек һәрнәрсәдә сизелә. Цехлар, завод ишек алды, клуб һәм завод фасады рәсемнәр, плакатлар белән бизәлгән. Бәйрәм көннәрендә цехларда җыелышлар, беседалар, ә завод клубында тантаналы җыелыш үткәреләчәк.

Сөекле Кызыл Армиябезнең еллыгын фанерачылар әнә шулай каршылыйлар.

И. ФӘЙЗУЛЛИН,
Зеленодольск.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР ЛЮБОТИН, МЕРЕФА, ОБОЯНЬ ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1) 19 нчы февральдә безнең гаскәрләр, Харьковтан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, ЛЮБОТИН шәһәрен һәм тимер юл станциясен, МЕРЕФА шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

2) Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр, кискен атака нәтиҗәсендә, ОБОЯНЬ шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар. Дошманның чолганып алынган гарнизоны юк ителде һәм бер өлеше плен алынды. КУРСК—ХАРЬКОВ тимер юлы һәм шоссе юлы тулысынча дошманнан чистартылды.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Совет Информбюросыннан

19 нчы ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

19 нчы февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга киттеләр. Безнең частьлар немецларны халык яши торган тагын күп кенә пунктлардан бәреп чыгардылар. Плен алынган немец солдатларының һәм офицерларының әйтүенчә, соңгы сугышларда немецларның 403 нче сакчы дивизиясе тар-мар ителгән. Бу дивизия полицейскийлардан һәм жандармнардан төзелеп, сугышка күптән түгел генә кертелгән булган. Дивизиянең туздырылган частьларының калдыклары безнең гаскәрләрнең ударлары астында тәртипсез рәвештә чигенәләр.

* * *

Ровеньки районында безнең частьлар һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер эшчеләр поселогы өчен булган сугышта 7 орудие, эре калибрлы 5 пулемет, 7 тягач, йөк төялгән 15 повозка һәм 17 автомашина кулга төшерелде. Икенче бер участокта дошманның ике рота пехотасы чолгап алынды һәм юк ителде.

* * *

Краматорская районында бер участокта гитлерчылар контратака ясаганнар иде, ләкин үзләре өчен зур югалтулар белән алып ташландылар. Сугыш кырында немецларның яндырылган 6 танкысы һәм 200 гә якын үле гәүдәләре калды.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак, Н-че часть участогында, гитлерчылар контратакага, 20 танк белән бергә, ике пехота полкының калдыкларын җибәрделәр. Совет сугышчылары, пехота коралларыннан атып, гитлерчыларны туктаттылар һәм җиргә ятырга мәҗбүр иттеләр. Шул арада безнең моторлаштырылган ике подразделениебез дошманга флангылардан һәм тылдан удар ясадылар. 300 гә якын солдатлары һәм офицерлары үтерелгәннән соң немецлар тиз генә чигенделәр. 7 танк, 4 самоход орудие, 12 пулемет, алты көпшәле 2 миномет һәм сугыш припаслары төялгән 19 автомашина кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан төньяктарак Н-че берләшмә частьлары халык яши торган 10 пунктны алдылар һәм 8 орудие, 20 мотоцикл, 170 велосипед, 2 сугыш припаслары складын һәм башка төрле хәрби милекләр кулга төшерделәр.

* * *

Украина партизаннарының бер отряды, Кызыл Армиянең һөҗүм итеп килүче частьлары белән берлектә хәрәкәт итеп, шоссе юлында засада ясады. Партизаннар, мылтык һәм пулеметлардан атып, совет гаскәрләренең ударлары астында тәртипсез рәвештә чигенеп баручы 200 гә якын гитлерчыларны кырдылар. Икенче бер шоссе юлында шул ук отрядның партизаннары 235 ат, 130 винтовка, берничә пулемет һәм минометлар кулга төшерделәр.

* * *

Курск өлкәсендәге Новоселовка авылы аркылы чигенгән чакта немец-фашист кабахәтләр авыл халкын талап киткәннәр. Үзләре белән алып китәргә мөмкин булмаган барлык нәрсәләрне бу юлбасарлар бозганнар һәм яраксыз хәлгә китергәннәр. Гитлерчыларның бер группасы колхозчы Дмитрий Серенконың йортына бәреп кергән, аның 15 яшьлек малаен тотып алган һәм аны ерткыч төстә җәзалаган. Бандитлар колхозчы Евдокия Лелинаның йортын яндырганнар. Лелина һәм аның кызы Зоя янып торган йорттан йөгереп чыккан, фашист ерткычлар аларны автоматлардан атып үтергәннәр.

* * *

Шалон-Сюр Саонда Франциянең азат укчылары немецларның совет-немец фронтларына солдатлар төяп бара торган бер хәрби эшелонын һәлак итүне оештырганнар. Һәлакәт поездның бөтен тизлек белән бару вакытында булган. 250 дән артык гитлерчы үтерелгән. Яраланган немец солдатларының һәм офицерларының саны үлүчеләрдән күп тапкыр артык.

19 нчы ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

19 нчы февральдә безнең гаскәрләр Харьковтан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, **Люботин** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, **Мерефа** шәһәрен һәм тимер юл станциясен, халык яши торган зур пунктлардан **Ольшаныны, Пересечнаяны, Песочинны, Высокийны, Комаровканы, Покотиловканы** алдылар.

Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр **Обоянь** шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

Краснодар районында безнең гаскәрләр район үзәге **Поповическаяны**, халык яши торган зур пунктлардан **Гривенскаяны, Новониколаевскаяны, Андреевскаяны, Новеличковскаяны** алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

18 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 15 артиллерия һәм 8 миномет батареясының утын бастырдылар һәм 5 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че часть су чиге аркылы кинеп чыкты һәм немецларның каршылык күрсәтүен бастырып, дошман оборонасының бер ныгытылган узелын алды. Сугыш кырында дошманның 200 дән артык үле гәүдәләре калды. Бер самоход орудие, 2 танк, 13 автомашина, бер радиостанция кулга төшерелде һәм берничә дистә пленный алынды.

* * *

Красноармейское районында безнең гаскәрләр дошманга каршы каты сугышлар алып бардылар. Н-че часть сугышчылары, гитлерчыларның берничә контратакасын кире кайтарып, алга киттеләр һәм дошманның ныгытылган позицияләрен алдылар. Бу сугышта немецларның 300 солдатлары һәм офицерлары үтерелде. Дошманның 4 танкысы зарарланды һәм яндырылды.

* * *

Грайворон районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Дошманга каршы бик каты сугышта Н-че часть сугышчылары немецларның халык яши торган бер пунктта оборонада торучы 2 полкының калдыкларын юк иттеләр. Урам сугышларында 600 гә якын гитлерчы кырып ташланды. Дошманның 8 танкысы һәм 15 автомашинасы зарарланды һәм яндырылды. Ике танк, 4 орудие, 23 автомашина, ягулык тутырылган 7 цистерна һәм сугыш припаслары тутырылган 2 зур склад кулга төшерелде. Икенче бер участокта немецларның бер батальонга якын пехотасы юк ителде һәм 300 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең частьлар дошманны кысрыклауны дәвам иттерделәр. Немецлар фронтның бу участогына ашыгыч рәвештә резервлар китерәләр. Соңгы сугышларда немецларның 327 нче пехота дивизиясенең шушы көннәрдә генә Франциянең Лион шәһәреннән килгән подразделениеләре катнашканлыгы беленде. Н-че часть сугышчылары халык яши торган һәм көчле итеп ныгытылган бер пунктны алдылар һәм шул вакытта 200 гә якын гитлерчыны кырдылар. 2 орудие, 13 пулемет һәм зур сугыш припаслары складлары кулга төшерелде.

* * *

Фатеждан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть алга таба барып, 400 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырды, 100 гә якын кешене плен алды. 8 орудие, ашлык һәм төрле сугыш милекләре тутырылган 6 склад кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар 60 немец солдатын һәм офицерын плен алдылар. 2 танкетка, 18 орудие, 50 пулемет, 100 автомат, 300 винтовка, 34 автомашина, 10 мотоцикл, 30 ат, 100 повозка, азык һәм әйберләр тутырылган 5 склад кулга төшерелде.

* * *

Краснодар краеның бер районында хәрәкәт итүче, «Мститель» исемле партизаннар отряды берничә урында тимер юлга миналар куйган. Партизаннар куйган миналарга бәрелеп, немецларның 2 хәрби эшелоны шартлаган.

* * *

Немецларның 111 нче пехота дивизиясенең 70 нче полкының 10 нчы ротасыннан плен алынган унтер-офицер Отто Бауэр болай диде: «Русларның басымы астында без Кавказдан чигенә башлагач батальон командиры, без фронт линиясен тигезлибез һәм Георгиевск районында тукталачакбыз диде. Ләкин озакламый хәл үзгәреп китте. Чигенүнең икенче көнендә полк командиры майор Никкель үзен авыру дип игълан итте һәм җиңел машинага утырып китеп барды. Руслар безне куып килделәр һәм безнең барлык коммуникацияләребезне алдылар. Өченче көнне бездә паника башланды». Шул ук дивизиянең 50 нче полкының 2 нче ротасыннан плен алынган унтер-офицер Вилли Лемке һәм ефрейтор Гергард Грюнер болай диделәр: «Баштарак без үз-үзебезне белешмичә алга омтылдык һәм һәрбер шәһәр өчен, һәрбер станица өчен бик кыйммәт түләдек. Хәзер инде моннан китү өчен, яки, безнең арада әйтелгәнчә, «дошманнан аерылу» өчен без шулай ук авыр югалтулар бирәбез. Безнең дивизиябез чигенгән чакта бөтенләй хәлсезләнделәр. Роталарда 20 шәр—30 ар кеше генә калды. Бик күп солдатлар үтерелде яки яраланды. Күп кешеләр плен төште».

* * *

Ставрополь краенда Кызыл Армия частьлары азат иткән Спицевское авылында торучылар немец бандитларының совет гражданнарын коточкыч төстә җәзалаулары турында сөйләделәр. Спицевское авылында торган чакта гитлерчылар картлардан, хатын-кызлардан һәм балалардан 178 кешене газаплап үтергәннәр. Немецлар авыл кешеләрен кабер казырга мәҗбүр иткәннәр, соңыннан аларны 20 шәр кешедән торган группалар итеп чокырлар янына куып алып киткәннәр һәм шунда үтергәннәр.

„ХАРЬКОВНЫ АЛУ СОВЕТ ХАЛКЫНЫҢ АЗАТЛЫК КӨРӘШЕНДӘ АНЫҢ ДАНЫН АРТТЫРА"

Совет гаскәрләренең яңа җиңүе турында Англия

ЛОНДОН, 17 февраль. (ТАСС) Кичә кич белән, совет гаскәрләренең Харьковны алулары турында хәбәр килү белән үк, Лондон радиосы бу турыда бөтен илгә хәбәр итте. Бу хәбәр берничә тапкыр тапшырылды. Радиокомментаторлар үзләренең обзорларын шушы хәбәргә багышлыйлар. Радиокомментатор Хейстингс болай ди: «Кызыл Армиянең Харьковны алуы Совет—Германия фронтындагы көрәшнең яңа этабы дигән сүз һәм ул Кызыл Армия алдында киң перспектива ача. Харьковны алу нәтиҗәсендә Кызыл Армия дошманга яңа авыр ударлар ясый алачак».

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, Лондондагы барлык газеталар совет гаскәрләренең яңа җиңүенең зур стратегик әһәмияте барлыгын бер тавыштан әйтәләр. «Дейли телеграф энд Морнинг пост» газетасы болай дип яза: «Гитлер командованиесе шәһәрне ничек кенә итеп булса да саклап калырга уйлаган иде. Немецлар, яз җитү белән, юл өзелгәч, совет гаскәрләренең Харьковны алулары тормышка ашмаслык мәсьәлә булачак дип өметләнгәннәр иде. Ләкин немецларның бу өметләре Россия карларыннан да элегрәк эреп юкка чыктылар».

«Дейли экспресс» газетасы үзенең баш мәкаләсендә болай дип яза: «Кызыл Армиянең яңа җиңүе немец гаскәрләренең рухын тагын да төшерер. 1943 нче елны без эшне Европа континентында тәгәлләргә тиешбез».

Англиянең мәгълүм публицисты Гарвин «Санди экспресс» газетасында басылып чыккан мәкаләсендә болай ди: «Советларның яңа җиңүләре үзләренең әһәмияте ягыннан, иң югары дәрәҗәдә тора. Кызыл Армиянең уңышлары гитлеризмны тирәнтен какшаттылар. Кызыл Армия, үзенең җиңүләре белән, Рузвельтның һәм Черчилльнең Касабланкадагы очрашулары вакытында уйларга мөмкин булганга караганда тагын да киңрәк мөмкинлекләр ачты. Көнбатыш демократияләр үзләренең карамакларында булган барлык көчләр белән, күптән үк инде рус армияләренә һәм рус халкына ярдәмгә барырга тиешләр иде. Европада Гитлерга каршы көнбатыш державалар һәм Россия тарафыннан ясалачак икеләтә удар быел ук гитлеризмны тар-мар итүне тизләтәчәк».

„ХАРЬКОВНЫҢ АЛЫНУЫ—ГЕРМАНИЯ АРМИЯСЕНӘ ЯСАЛГАН ТИҢДӘШСЕЗ КӨЧЛЕ ЯҢА УДАР"

Совет гаскәрләренең һөҗүме турында Америка

НЬЮ-ЙОРК 17 февраль. (ТАСС). Америка радиостанцияләре, үзләренең гадәттәге программаларын бүлеп торып, совет гаскәрләренең Харьковны алулары турындагы хәбәрләрне киң күләмдә тапшырдылар. Вашингтон радио күзәтчесе Суинг болай диде: «Совет гаскәрләренең Харьковны алулары Германия гаскәрләре өчен яңа куркыныч тудыра һәм ул—Германия армиясенә ясалган тиңдәшсез көчле яңа удар».

Сан-Франциско радиосы, Харьковның алынуы Германия оборонасының төп терәк пунктларының берсеннән мәхрүм булуы дигән сүз, ди.

«Нью-Йорк геральд трибюн» газетасының фикеренчә, Кызыл Армия инде күчәр державаларының җиңелүенә нигез салды. Кызыл Армия асылда сугышның барышын үзгәртте. Гитлерга мөмкин кадәр тизрәк куәтле удар ясау өчен русларның уңышларыннан союзникларның файдалануы хәрби яктан караганда бик әһәмиятле.

Франция пароходларының АКШ ка килүе

Франциянең хәрби диңгез миссиясе союзниклар флотына кушылган «Ришелье» линкорының һәм Франциянең башка сугыш пароходларының Нью-Йоркка килгәнлекләрен хәбәр итә. «Ришелье» линкоры Нью-Йоркка Жиро приказы буенча җибәрелгән.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность-транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1049 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 273